Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

___16.08.2024_________ Менделеевск ш. № __502__________

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районының җайга салынмый
торган тарифлар буенча автомобиль
транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны
гамәлгә ашыру хокукына ачык
конкурсны оештыру турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарны, үтәү йөзеннән « Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 26 декабоендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законын, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык рәсмиләштерү һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты карталарын яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында»2021 елның 29 июлендәге 559 номерлы карарын үтәү йөзеннән

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск шәһәре территориясендә автомобиль транспортында пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хокукына җайга салынмый торган тарифлар буенча түбәндәге муниципаль маршрутлар буенча ачык конкурс үткәрергә:

- №101 Шәһәр" Универсал+" офисы - Ушковлар утары"- "Универсал+" офисы
- №104 Шәһәр " Универсал+" офисы – Монай - "Универсал+" офисы

2. Конкурс комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С. В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Килештерелгән:
Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Башкарма комитет җитәкчесенең
шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В.Метальников

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның 16 августындагы
502 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының җайга салынмый торган тарифлар буенча автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурс оештыру буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчсе - Р.Р. Искәндәров;

Комиссия секретаре:

“Менделеевск муниципаль районының административ-хуҗалык идарәсе " МБУ директоры– Д.М. Миңнеханов

Комиссия әгъалары:

- Башкарма комитет җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары - С.В. Метальников;

«Менделеевск муниципаль районының инфраструктура һәм инвестиция үсеше идарәсе " МАУ башлыгы – П. А. Маштаков

Менделеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе - М.В.Григорьев (килешү буенча)